ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

27.06.2024 № 581

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2017 елның 14 мартындагы 634 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең 2.7 пунктында «Россия Федерациясе Пенсия Фондының» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фондының» сүзләренә, «Россия Федерациясе Пенсия фондында» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фондында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин